Урта Кумор авыл җирлеге Советы

# КАРАР

17 декабрь, 2024 ел №39

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 20 ноябрендәге 34 номерлы Урта Кумор авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 6 статьясындагы 3 өлеше, 32 бүлеге нигезендә Урта Кумор авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 20 ноябрендәге 34 номерлы Урта Кумор авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) түбәндәгеләргә карата 0,1 процент:

гаражларга һәм машина урыннарына, шул исәптән әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнарга карата;

һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелмәләр;

2) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясының 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата (әлеге пунктның 5 пунктчасында күрсәтелгән салым салу объектларыннан тыш), шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент;

3) фатирларга, фатир өлешләренә, бүлмәләргә карата 0,2 процент;

4) түбәндәгеләргә карата 0,3 процент:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

- составына ким дигәндә бер торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;

- төзелеп бетмәгән объектлар, әгәр мондый объектларның проектлана торган максаты торак йорт булса;

5) 2025 елда – 1,2 процент; 2026 елда – 1,2 процент; 2027 елда – 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда 2 процент гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган Исемлеккә кертелгән урыннарга карата.

6) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган салым салу объектларына карата 2,5 процент;

7) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы С.В.Федоров